Аксубай муниципаль районы Беловка авыл жирлеге Советы
423050 Аксубай районы,Яңа Үзи авылы,
Мәктәп урамы, 7 нче йорт

Совет Беловского сельского поселения Аксубаевского муниципального района
423050 Аксубаевский район,с.Новое Узеево улица Школьная, д.7

Тел. (8-84344-4-08-19) ОГРН 1061665003212,
ОКПО 04306440, ИНН/КПП 1603005000/160301001
E-mail: *Belov.Aks@tatar.ru, sovet.belov@mail.ru*

---

Татарстан Республикасы
Аксубай муниципаль районы
Беловка авыл җирлеге башлыгы
**КАРАР**

№7 14.11.2023 ел

Аксубай муниципаль районы Беловка авыл җирлегенең
Яңа Үзи авылында гражданнарның
үзара салым чараларын кертү һәм куллану
мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында».

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьяларына, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел, №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясына, Аксубай муниципаль районы «Беловка авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 24 статьясына ярашлы

Карар итәм:

1. 2023 елның 23 ноябрендә ТР, Аксубай районы, Яңа Үзи авылы, Мәктәп урамы, 7 йорт адресы буенча урнашкан мәдәният йорты бинасында 10 сәгать 00 минутка Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Беловка авыл җирлегенең Яңа Үзи авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыены билгеләнсен.
2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга::
3. Сез 2024 елда Аксубай муниципаль районы Беловка авыл җирлеге Яңа Үзи авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, (I төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, хәрби хезмәткә чакырылган, өлешчә мобилизацияләнгән затлардан,контракт буенча хәрби бурычын үтәүчеләрдән һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш), 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтүгә ризамы:

**1.Беловка авыл җирлегенең Яңа Үзи авылы чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге**

- Торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау,тоту (Яңа Үзи торак пункты чикләрендә юл япмасын төзү, шул исәптән: туфракны күтәрү, гредировкалау, вак таш салу, тигезләү (килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү, вак таш сатып алу, авыл юлларына вак таш салу),

Беловка авыл җирлегенең Яңа Узи торак пункты чикләрендә юлны кышкы тоту (юлларны кардан чистарту, запас частьләр һәм җиһазлар сатып алу; килешү буенча эш һәм хезмәтләр өчен түләү, ягулык-майлау материаллары сатып алу).

**2.Торак пункт чикләрендә халыкны су белән тәэмин итүне, су чыгаруны, халыкны ягулык белән тәэмин итүне Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән вәкаләтләр чикләрендә оештыру:**

-су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу системаларын, су күтәрү манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортлауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итүче башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау (суүткәргеч челтәрен ремонтлау, материаллар сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү).

**3. Торак пункт территориясен төзекләндерүне оештыру (урамнарны яктыртуны да кертеп):**

- урамнарны яктырту җайланмасы (Яңа Үзи торак пункты чикләрендә урамнарны яктыртуны оештыруны тәэмин итү өчен килешү буенча товарлар сатып алу, эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү)).

« РИЗА» «КАРШЫ».

3. Әлеге карарны Беловка авыл җирлеге мәгълүмат стендларында, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет челтәрендә урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга (http://aksubayevo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга (http://pravo.tatarstan.ru).

4. Әлеге карар басылып чыккан көннән үз көченә керә.

Аксубай муниципаль районы
Беловка авыл җирлеге башлыгы И. Р. Мәхмүтов